ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.12.2021 г. Заинск № 475

**«Зәй муниципаль районының авыл җирлекләре территориясендә урнашкан муниципаль торактан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондының торак урыннарын карап тоткан һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайламаган торак милекчеләре өчен түләү күләме турында»**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы авыл җирлекләре халкы өчен расларга:

социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннарның милекчеләре өчен торак урынын карап тотуга түләү күләмен 1 кушымта нигезендә;

Зәй муниципаль районы муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләмен (наемга алу өчен түләү) 2 кушымта нигезендә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. «Зәй муниципаль районының авыл җирлекләре территориясендә урнашкан муниципаль торактан файдаланган өчен (наем өчен түләү),

муниципаль торак фондының торак урыннарын карап торткан һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайламаган торак милекчеләре өчен өчен түләү күләме турында» 20120 елның 25 декабрендәге 605 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Тораактан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме 2018 елның 26 ноябрендәге 1758 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Зәй муниципаль районында социаль наем килешүләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннарын биләүчеләр өчен тораактан файдаланган өчен түләү күләмен (наем өчен түләү) исәпләү методикасы нигезендә исәпләнә.

5. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Юрист

М.М. Хәбибуллин
3 41 33

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елнның 22. 12
745 номерлы карарына
1 кушымта

**Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча тортактан файдаланучылар өчен торакны тоту өчен түләү күләме, һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайламаган торак милекчеләре өчен торакны карап тоту өчен түләү күләме**

| № п/п | Хезмәтнең исеме | Хезмәтне исәпләү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне исәпләү өчен тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 1.01.2022 ел-30.06.2022ел. | 1.07.2022 ел - 31.12.2022ел. |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 1,64 | 1,70 |
| 2 | Торак бинага агымдагы ремонт | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 2,20 | 2,30 |
| 3 | Йорт эчендәге санитар-техник челтәрләргә агымдагы ремонт | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 1,65 | 1,70 |
| 4 | Йорт эчендәге үзәк җылыту челтәренә агымдагы ремонт | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 1,45 | 1,50 |
| 5 | Йорт эчендәге газ белән тәэмин итү челтәренә агымдагы ремонт | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 0,23 | 0,24 |
| 6 | Йорт эчендәге электр челтәренә агымдагы ремонт | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 0,90 | 0,95 |

**Эшләр идарәчесе** **Т.А. Лоптова**

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 22. 12
775 номерлы карарына
2 кушымта

**Зәй муниципаль районында социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торактан файдаланган өчен түләү күләме (наем өчен түләү)**

| Адрес | | **Торак урынны наемга алган өчен түләү күләме,** (аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. метрыннан) 1.01.2022 елдан 31.12.2022 елга кадәр. |
|---|---|---|
| 1 | Александр Бистәсе, Яңа урам, 35 йорт | 7,9 |
| 2 | Бохарай, Ромашкино, 1 йорт | 7,9 |
| 3 | Бохарай, Ромашкино, 2 йорт | 7,9 |
| 4 | Бохарай, Ромашкино, 3 йорт | 8,1 |
| 5 | Поручик, Яңа урам, 11 йорт | 7,9 |
| 6 | Поручик, Яңа урам, 12 йорт | 7,9 |
| 7 | Сарсаз-Баграж, Яшьләр урамы, 1 йорт | 7,9 |
| 8 | Сарсаз-Баграж, Яшьләр урамы, 2 йорт | 7,9 |
| 9 | Сарсаз-Баграж, Яшьләр урамы, 3 йорт | 7,9 |
| 10 | Урсай, Үзәк урам, 3 йорт | 7,9 |
| 11 | Урсай, Үзәк урам, 4 йорт | 8,1 |
| 12 | Якты Күл, Академик Гортышев урамы, 7 йорт | 8,1 |
| 13 | Якты Күл, Академик Гортышев урамы, 9 йорт | 8,1 |
| 14 | Иске Маврин, Үзәк урам, 1 йорт | 7,9 |
| 15 | Иске Маврин, Үзәк урам, 2 йорт | 7,9 |
| 16 | Бигеш, Гагарин урамы, 125 йорт | 8,1 |
| 17 | Бохарай, Яңа урам, 4 йорт | 8,3 |

**Эшләр идарәчесе** **Т.А. Лоптова**